**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«27» декабрь 2024ел № 180

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 09 апрелендәге 173 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 20 июнендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 09 апрелендәге 173 номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (алга таба текст буенча - регламентлар) (30.12.2013 № 807, 16.07.2014 № 304, 20.07.2015 № 391, 20.05.2016 № 485, 10.11.2016 № 1051, 03.07.2017 № 368, 12.09.2017 № 531, 12.09.2017 № 532, 16.10.2017 № 621, 25.12.2017 № 799, 26.06.2018 № 392, 07.11.2018 № 701, 20.03.2019 № 149, 21.01.2020 № 18, 17.06.2020 № 263, 15.12.2020 № 560, 30.12.2020 № 598, 29.01.2021 № 30, 29.01.2021 № 31, 01.02.2021 № 38, 19.03.2021 № 111, 29.03.2021 № 136, 07.04.2021 № 156, 08.04.2021 № 159, 25.06.2021 № 215, 20.12.2021 № 307 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карарның 1.1 пункты белән расланган «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасы буенча торак сатып алуга (төзелешкә) социаль түләү алуга хокук турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты:

- таблицаның 2.5 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт белән тулыландырырга:

«5.1) әгәр мондый килешү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 40.1 ст. каралган булса, капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше сыйфатын килештерү;»;

2) күрсәтелгән карарның 1.3 пункты белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аерым категориядәге гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты:

- 2.6 пунктының 3 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

- 3.5.1 пунктының 3 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

3) күрсәтелгән карарның 1.9 пункты белән расланган Торак урыннарны алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты:

- 2.5 пунктның 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

4) күрсәтелгән карарның 1.10 пункты белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты:

- 1.5 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясының 6 өлешендә билгеләнгән билгеләргә туры килә торган бина күпфатирлы йорт дип таныла.»;

5) күрсәтелгән карарның 1.76 пункты белән расланган 1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышы ветераннарының гаилә әгъзаларын (тол хатыннарын) исәпкә кую һәм торак шартларын яхшыртуга аларга субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты:

- 2.5 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның хезмәт эшчәнлеге, Хезмәт стажы турында (2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен) документлар, шулай ук җитештерүдә бәхетсезлек очрагын яисә һөнәри авыруны тикшерү нәтиҗәләре буенча рәсмиләштерелгән документлар;»;

6) үз көчен югалтканнар дип танырга:

- күрсәтелгән карарның 1.2 пункты белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.5 пункты белән расланган Торак урынны үзгәртеп коруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.7 пункты белән расланган Гражданнарның милкенә торак урыннарны тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.8 пункты белән расланган Социаль наем шартнамәсе нигезендә гражданга муниципаль милектәге торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.11 пункты белән расланган Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.12 пункты белән расланган Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.13 пункты белән расланган Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.16 пункты белән расланган Биналар һәм корылмалар төзү өчен җир эшләрен җитештерүгә ордер бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.30 пункты белән расланган Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча авыр йөк ташуга, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

- күрсәтелгән карарның 1.54 пункты белән расланган Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын туктату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин